ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Центральная, дом 13,
село Старое Дрожжаное, 422470

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк урам, 13 нче йорт,
Иске Чүпрәле авылы, 422470

Тел.: (84375) 2-23-50, 2-21-70, факс: (84375) 2-22-71, e-mail:chuprale@tatar.ru, www.drogganoye.tatarstan.ru

28.10.2025 № 2102/И
№ ___________ ________________

## Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү

**Әлеге хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез:** Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксы авыл җирлегенең Генераль планы проекты (алга таба - проект).

**Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**

1) территориаль планлаштыру турында Нигезләмә (график материаллар белән);

2) генераль планны нигезләү материаллары. Аңлатма язуы (график материаллар белән);

3) нигезләү материаллары текст формасында. Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм территориядә инженерлык әзерлеге чаралары, гражданнар оборонасы чаралары, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары исемлеге (график материаллар белән).

**Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2025 елның 28 октябрендәге 33 номерлы карары нигезендә, проект буенча гавами тыңлаулар 2025 елның 31 октябреннән 21 ноябрьгә кадәр үткәрелә.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру процедурасы түбәндәге этапларны үз эченә ала:

- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм проект экспозициясен ачу;
- проект экспозициясен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

- Төзелеш проекты әзерләнгән Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлегендә даими яшәүче гражданнар;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

**Гавами тыңлаулар уздырыла торган территория:** Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге.

**Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен ачу урыны һәм датасы:**

- Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Үзәк ур., 13 йорт, Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге - 2025 елның 7 ноябре.

**Проект экспозициясен үткәрү сроклары:** 2025 елның 7 ноябреннән 17 ноябренә кадәр.

**Экспозицияләргә бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:** эш көннәрендә экспозицияне уздыру вакыты 08:00 дән 12:00 сәгатькә кадәр һәм 14:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр.

**Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:**

2025 елның 7 ноябреннән 17 ноябренә кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация үткән гавами тыңлауларда катнашучылар түбәндәге проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайты ярдәмендә (https://droganoye.tatarstan.ru);
- Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре (функцияләре) кире элемтә порталы (https://pos.gosuslugi.ru) ярдәмендә;
- язмача яисә электрон документ рәвешендә гавами тыңлауларны оештыручы - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты адресына: 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Үзәк ур., 13 йорт;
- Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле районы, Үзәк урамы, 13 йорт, Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге (эш көннәрендә 08:00 дән 12:00 сәгатькә кадәр һәм 14:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен китапта (журналда) исәпкә алу юлы белән.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 маддәсенең 12 нче өлеше нигезендә идентификация үткән гавами тыңлауларда катнашучылар

гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышлары барышында язма яисә телдән проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү хокукына ия.

**Гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

- Зур Акса авылы торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Зур Акса авылы, Киров ур., 1 йорт, мәдәният йортының тамаша залында, 2025 елның 18 ноябрендә 09:00 сәгатьтә;
- Чуаш Бизнәсе авылы торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Чуаш Бизнәсе авылы, Горький урамы, 4 йорт, авыл клубының тамаша залында, 2025 елның 18 ноябрендә 10:00 сәгатьтә.

**Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайтлар турында мәгълүмат:**

- Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (https://droganoye.tatarstan.ru) 2025 елның 7 ноябреннән «Район турында - Территориаль планлаштыру - Авыл җирлекләренең Генераль планы - Зур Аксу СП Генераль планы - Зур Аксу СП Генераль планы (https://droganoye.tatarstan.ru/ekspozitsia-proekta-generalnopla 638929.htm);
- Россия Федерациясе дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https://pos.gosuslugi.ru) 2025 елның 7 ноябреннән «Иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар» бүлегендә (https://pos.gosuslugi.ru/lkp/public-discussions).

**Әлеге хәбәрнамәне бастырып чыгарырга:** «Туган як» район газетасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://droganoye.tatarstan.ru), Зур Аксу авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе

Р.И. Мөхәммәтҗанов